ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«18» октябрь 2019 ел** **№ 806**

**“Арча муниципаль районында 2017-2021 елларга мәгариф үсеше” муниципаль программасын раслау турында” башкарма комитетның 2017 елның 6 апрелендәге 360 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча районы башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. “Арча муниципаль районында 2017-2021 елларга мәгариф үсеше” муниципаль программасын раслау турында” Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 апрелендәге 360 номерлы карарына (2017 елның 28 декабрендәге 1498 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарлары аша кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа исемендә “2017-2021”санын “2017-2022” санына алмаштырырга;

Программаның паспортында:

“Программаның исеме” бүлегендә “2017-2021”санын “2017-2022” санына алмаштырырга;

“Программаның төп бурычлары” бүлегенең унбишенче абзацында “2017-2021”санын “2017-2022” санына алмаштырырга;

“Программаны тормышка ашыру вакыты” бүлегендә “2017-2021” санын “2017-2022” санына алмаштырырга;

Программаның паспортында “Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары” бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “2017-2022 елларга Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларының гомуми күләме 4689816,1 мең сум тәшкил итә:

| Финанслау чыганагы | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Республика бюджеты | 573555,5 | 646357,7 | 670832,6 | 663652,8 | 680941,2 | 713748,2 |
| Җирле бюджет | 136627,9 | 145224,9 | 120008,9 | 131213,7 | 118050,7 | 89602,0 |
| Бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | |
| Барлыгы | 710183,4 | 791582,6 | 790841,5 | 794866,5 | 798991,9 | 803350,2 |

1 бүлектә программаның исемендә “2017-2021”санын “2017-2022” санына алмаштырырга;

2 бүлекнең егерме икенче абзацында “2017-2021”санын “2017-2022” санына алмаштырырга;

“Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү” дигән 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2017-2022 елларга Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларының гомуми күләме 4689816,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Финанслау чыганагы | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Республика бюджеты | 573555,5 | 646357,7 | 670832,6 | 663652,8 | 680941,2 | 713748,2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Җирле бюджет | 136627,9 | 145224,9 | 120008,9 | 131213,7 | 118050,7 | 89602,0 |
| Бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | |
| Барлыгы | 710183,4 | 791582,6 | 790841,5 | 794866,5 | 798991,9 | 803350,2 |

Программаны финанслау күләме фаразлау характерына ия һәм билгеләнгән тәртиптә, һәр елга тиешле дәрәҗәдәге бюджет формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелү тиешле".

"Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү" дигән 5 бүлекнең дүртенче абзацында "2017-2021" санын "2017-2022" санына алмаштырырга;

5 бүлектә "Программаның нәтиҗәлелеген индикатив күрсәткечләр нигезендә бәяләү» дигән таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Юнәлешләр буенча максатчан күрсәткечләр | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Системаны үстерү һәм белем бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | |
| 1.1. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гомуми санында мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мәктәпкәчә белем алуга җәлеп ителгән өлеше, | 62 | 62 | 65 | 70 | 70 | 78 |
| 1.2. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрмәүче балаларны җәлеп итү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 1.3. | 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларның гомуми санында төрле оештыру-хокукый формадагы һәм милек рәвешендәге оешмаларда балаларны карау буенча мәктәпкәчә хезмәтләр һәм (яки) хезмәт күрсәтүләр алучы 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 1.4. | Мәктәпкәчә яшьтәге мәктәпкәчә учреждениеләргә йөрүче татар балаларының гомуми санында ана телендә тәрбияләнүче | 61,8 | 77 | 86 | 90 | 90 | 90 |
| 1.5. | Укытучыларның гомуми санында мәктәпкәчә белем бирүне оештыруга федераль дәүләт таләпләрен кертү мәсьәләсе буенча укулар узган педагогларның өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 1.6. | Һөнәри эшчәнлекләрендә заманча белем бирү технологияләрен (шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен) нәтиҗәле кулланучы педагоглар өлеше, % | 60 | 65 | 72 | 75 | 80 | 92 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.7. | Педагогларның гомуми санында беренче һәм югары квалификация категорияләренә ия булган педагоглар өлеше, % | 76 | 77 | 78 | 79 | 80 | 80 |
| 1.8. | Бер баланың елына авыру буенча килмәгән көннәр саны | 4 | 4 | 3,7 | 3,5 | 3 | 3 |
| 1.9. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларның гомуми санында авырмаган балалар өлеше, % | 30 | 32 | 35 | 38 | 40 | 43 |
| 1.10. | Сораштырылучылар арасыннан мәктәпкәчә белем бирү сыйфатыннан канәгать булганнар | 93 | 95 | 96 | 97 | 98 | 98 |
| 1.11. | 1-6 яшьләрдәге балаларның гомуми санында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә билгеләү өчен исәптә торучы 1-6 яшьлек балалар өлеше, % | 32 | 34 | 35 | 33 | 30 | 27 |
| **2. Икътисадны яңача үстерү бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән заманча белем бирү моделен төзү һәм сыйфатны бәяләү системасын үстерү** | | | | | | | |
| 2.1. | Муниципаль мәгариф учреждениеләренең гомуми саныннан югары дәрәҗәдәге гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләренең өлеше, % | 5,7 | 5,7 | 8,5 | 8,5 | 8,5 | 16 |
| 2.2. | Мәктәпләрнең гомуми саныннан төп гомуми белем бирү стандартына күчүне гамәлгә ашырган гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше (гомуми саннан), % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 2.3. | Федераль дәүләт белем бирү стандартларын кертүне исәпкә алып, квалификация күтәрүе узган гомуми белем бирү учреждениеләре педагогларының өлеше (гомуми саннан), % | 85 | 95 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 2.4. | Компетентлы якын килүне исәпкә алып эшләнгән программа дәрәҗәсе булган гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 2.5. | Психологик агартулар һәм төрле формаларда ата-аналар укулары узган, шулай ук гомуми белем бирү мәсьәләләре буенча конференцияләрдә, форумнарда катнашучы ата- | 60 | 65 | 70 | 75 | 80 | 85 |
| 2.6. | Гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларның бердәм дәүләт имтиханында катнашканнары саныннан бердәм дәүләт имтиханын тапшыручылар өлеше, % | 99,0 | 99,2 | 99,5 | 100 | 100 | 100 |
| 2.7. | Урта гомуми белем алу турында аттестат алмаган муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар саны, кеше | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| **3. Мәгариф белән идарә итү системасының нәтиҗәлелеген арттыру** | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1. | «Дәүләт һәм муниципаль идарә», «Менеджмент», «Персонал белән идарә итү " программалары буенча яңадан укулар узган мәгариф учреждениеләре җитәкчеләре өлеше % | 95 | 97 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 3.2. | Белем бирү һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге турында бастырып чыгарылган (массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендә) ачык хисап булган мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 3.3. | Интернет челтәрендәге даими яңартылып торучы сайтлары булган гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 3.4. | Мәгариф учреждениесе белән идарә итүдә мәгълүмати технологияләр кулланучы җитәкчеләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 3.5. | Контракт биремнәре буенча эш системасына күчерелгән җитәкчеләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| **4. Педагогларның һәм мәгариф оешмаларының эш сыйфатын бәяләүнең яңа системасын булдыру** | | | | | | | |
| 4.1. | Ата-аналар арасында белем бирү хезмәтләренен сыйфаты белән канәгать булу буенча сораштырулар үткәрү (елга сораштырулар | 4 | 5 | 7 | 8 | 8 | 10 |
| 4.2. | Халыкның гомуми белем бирүнең сыйфаты белән канәгать булуы (сораштыруда катнашучылар санынннан %) | 86 | 88 | 89 | 90 | 90 | 95 |
| 4.3. | Бәйсез экспертлар җәлеп ителгән район чаралары саны, берәмлек | 30 | 32 | 33 | 35 | 35 | 37 |
| 4.4. | Рейтинг системалы мәгариф оешмалары булу (әйе, юк) | әйе | әйе | әйе | әйе | әйе | юк |
| 4.5. | Мәктәп эчендәге белем бирү сыйфатын бәяләү системалары булган мәктәпләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 4.6. | Профильле белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәктәпләр өлеше. % | 97 | 97 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 4.7. | Укучыларны югары баскычларда профильле белем алуга җәлеп итү, % | 83 | 84 | 86 | 100 | 100 | 100 |
| 4.8. | 9 нчы сыйныф укучыларын профиль алу алды белеме бирү буенча колачлау, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 4.9. | 9-10 сыйныф укучыларының һөнәри өстенлек мониторингы белән колачланган өлеше, % | 82 | 85 | 90 | 95 | 95 | 100 |
| 4.10. | Белем бирү процессын гамәлгә ашыру шартларына заманча таләпләргә җавап бирүче мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 70 | 80 | 80 | 90 | 90 | 96 |
| 4.11. | Мәгариф оешмаларының яңа уку елына әзерлеге, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| **5. Мәгариф системасының кадрлар потенциалын үстерү** | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.1. | Муниципаль мәгариф учреждениеләре педагогик хезмәткәрләре штатлары җыелу, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 5.2. | Беренче һәм югары категориягә ия булган педагогик хезмәткәрләр өлеше, % | 76 | 77 | 78 | 80 | 80 | 85 |
| 5.3. | Гомуми белем бирү учреждениеләре укытучыларының гомуми санында 5 елга кадәр педагогик эш стажына ия булучылар өлеше, % | 4,8 | 5 | 5,2 | 5,2 | 5,5 | 5,7 |
| 5.4. | Яңача эшчәнлек буенча бүләкләр алу өчен төбәк һәм федераль дәрәҗәдәге педагогик осталык бәйгеләрендә катнашучы педагогик хезмәткәрләр өлеше, % | 15 | 18 | 18 | 20 | 20 | 23 |
| 5.5. | Белем бирү учреждениеләрендәге педагогик хезмәткәрләрнең гомуми саныннан яңадан әзерлек укулары, квалификация күтәрүе узган (5 елга 1 тапкыр исәбеннән) педагогик хезмәткәрләр өлеше, % | 2,5 | 3,4 | 4,0 | 4,0 | 4,5 | 5 |
| **6. Заманча белем бирү стандартларын һәм технологияләрен гамәлгә кертү** | | | | | | | |
| 6.1. | Муниципаль мәгариф учреждениеләренең гомуми саныннан яңача белем бирү программалары, укыту технологияләре, ысул һәм формалар кертүче мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 70 | 72 | 75 | 80 | 80 | 92 |
| 6.2. | Мәктәпләрнең уку җиһазлары һәм техник чаралар белән тәэмин ителү өлешендә федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә торган предмет кабинетларының өлеше, % | 70 | 72 | 75 | 80 | 80 | 82 |
| **7. Милли мәгарифне үстерү** | | | | | | | |
| 7.1. | Укучыларны татар телен өйрәтүгә җәлеп итү (туган тел яки дәүләт теле буларак),% | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 7.2. | Татар балаларын ана телендә укыту белән тәэмин итү, % | 69,1 | 71,4 | 73,9 | 75,8 | 78,2 | 78,4 |
| 7.3. | Татар балаларын ана телендә тәрбияләү белән тәэмин итү, % | 71,1 | 77,4 | 75,9 | 78,8 | 80,2 | 80,5 |
| 7.4. | Этномәдәни рус компонентлы сыйныфлар (мәктәпләр) саны, берәмлек (мәктәп/сыйныф) | 1/7 | 1/7 | 1/6 | 1/6 | 1/6 | 1/5 |
| 7.5. | Татар телендә шәһәр һәм республика чараларында (конкурслар, конференцияләр, фестивальләр) катнашучы балалар өлеше, % | 48,8 | 49,3 | 49,8 | 51,3 | 52,0 | 52,7 |
| **8. Белем бирү киңлеген үстерү** | | | | | | | |
| 8.1. | Гомуми белем бирү мәктәбендә бер укучының компьютерга керү сәгате белән тәэмин ителеше, % | 23 | 23 | 23 | 23 | 23 | 23 |
| 8.2. | Челтәр берләшмәләре эшендә катнашучы педагоглар өлеше, % | 50 | 55 | 60 | 72 | 75 | 87 |
| 8.3. | Мәктәп фәнни җәмгыятьләре әгъзалары булган укучылар өлеше, % | 4,8 | 5 | 5,5 | 6 | 6 | 15 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8.4. | Укучыларның гомуми саныннан Бөтенроссия олимпиадасы этапларында, интеллектуаль конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә җиңүчеләр һәм бүләк алучылар өлеше, % | 3,7 | 4,3 | 4,5 | 5 | 5 | 8 |
| 8.5. | Чит телне тирәнтен өйрәнүче укучылар өлеше, % | 4,6 | 4,6 | 4,8 | 5,2 | 5,5 | 6 |
| 8.6. | Җәйге профильле тел өйрәнү сменаларында катнашучы укучылар саны, кеше | 80 | 80 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 8.7. | Интернет-форумнарда, конференцияләрдә, семинарларда катнашучы чит тел укытучылары өлеше, % | 50 | 55 | 60 | 60 | 60 | 67 |
| 8.9. | Техник юнәлештәге берләшмәләрдә эшләүче өстәмә белем бирү педагоглары өлеше, % | 50 | 55 | 60 | 60 | 60 | 65 |
| 8.10. | Балаларны өстәмә белем бирү белән колачлау, шул исәптән: | 93,0 | 93,0 | 93,0 | 94,0 | 95,0 | 96,0 |
| 8.11. | -техник һәм спорт-техник юнәлешле, % | 20 | 25 | 25 | 27 | 27 | 29 |
| 8.12. | -физкультура-спорт юнәлешендәге, % | 10,5 | 15 | 15 | 15 | 15 | 16 |
| 8.13. | - туристик-туган якны өйрәнү юнәлешендәге, | 8 | 8 | 8 | 8 | 8 | 10 |
| 8.14. | - экологик-биологик юнәлештәге, % | 10,5 | 10,5 | 10,5 | 10,5 | 10,1 | 10,1 |
| 8.15. | - сәнгать-иҗат юнәлешендәге, % | 32 | 37 | 37 | 37 | 37 | 42 |
| 8.16. | - башка юнәлешләрдәге, % | 10 | 5,5 | 5,5 | 2,5 | 2,9 | 3,3 |
| 8.17. | Татар телендә өстәмә белем алучы балалар өлеше, % | 65 | 65 | 68 | 68 | 68 | 70 |
| 8.18. | Арча районында яшәүче халыклар телендә өстәмә белем алучы укучылар өлеше (башка милләт балаларының гомуми санынннан) | 0,2 | 0,2 | 0,3 | 0,3 | 0,4 | 0,4 |
| 8.19. | Татар телендә профильле сменалар белән колачланган балалар өлеше (мәктәп яны, җәйге стационар, палаткалы лагерьлар),% | 21 | 21,5 | 22 | 25 | 25 | 26 |
| 8.20. | Тәрбиянең көн кадагындагы мәсьәләләре, шул исәптән балалар лидерлыгы проблемасы буенча, квалификация күтәрү курслары узган тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 8.21. | Балалар һәм яшүсмерләр арасында социаль булмаган күренешләрне булдырмау буенча яңа методикалар һәм технологияләр кертүче мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 8.22. | Музей педагогикасын кертүче учреждениеләр өлеше, % | 45 | 50 | 55 | 55 | 55 | 61 |
| 8.23. | Балалар һәм яшүсмерләрне хокукый агарту эшен иң яхшы оештыру буенча район проектлары конкурсында катнашучы мәктәпләр өлеше (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 8.24. | Хокукый тәрбия проблемалары буенча педагоглар өчен укыту семинарлары һәм тренинглар үткәрүдә катнашучы мәктәпләр өлеше ( % ) | 45 | 50 | 55 | 60 | 60 | 70 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8.25 | Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә тормышка ашырыла торган социаль әһәмияткә ия район проектлары саны, берәмлек | 7 | 8 | 9 | 10 | 10 | 18 |
| 8.27. | Мәктәпләр, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре базасында инновацион мәйданчыклар саны, берәмлек | 5 | 5 | 6 | 6 | 6 | 12 |
| 8.28. | Мәктәпләр, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре базасында төрле дәрәҗәдәге эксперименталь мәйданчыклар саны, берәмлек | 3 | 4 | 5 | 5 | 5 | 7 |
| 8.29. | Инновация һәм тәҗрибә – сынау уздыру эшчәнлеге мәсьәләләре буенча шәһәр семинарларында, түгәрәк өстәлләрдә катнашучы педагоглар саны, кеше. | 75 | 80 | 85 | 85 | 86 | 87 |
| 8.30. | Республика, бөтенроссия һәм халыкара проектларда һәм программаларында катнашучы гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше, % | 10 | 11 | 12 | 15 | 15 | 22 |
| 8.31. | Республика, бөтенроссия һәм халыкара проектларда һәм программаларда катнашучы педагоглар саны, кеше. | 55 | 60 | 65 | 70 | 70 | 80 |
| 8.32. | Республика, бөтенроссия һәм халыкара проектларда һәм программаларда катнашучы укучылар саны, кеше. | 55 | 57 | 68 | 120 | 120 | 150 |
| **9. Сәламәтлек саклау технологияләрен гамәлгә кертү һәм куркынычсыз белем бирү мохитен булдыру** | | | | | | | |
| 9.1. | Мәктәп укучыларының гомуми санынnan сәламәтлек төркеме беренче һәм икенче булган балалар өлеше, % | 68 | 70 | 72 | 75 | 75 | 75 |
| 9.2. | Сәламәтлек саклау программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 9.3. | Спорт берләшмәләрендә шөгыльләнүче укучылар өлеше, % | 82 | 83 | 85 | 85 | 85 | 87 |
| 9.4. | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлтелгән бөтенроссия, республика, район акцияләрендә, ярышларда катнашучы укучылар өлеше, % | 80 | 85 | 90 | 90 | 90 | 92 |
| 9.5. | Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 9.6. | Федераль дәүләт белем бирү стандартына күчерелгән укучыларны 2 тапкыр кайнар аш белән тәэмин итү, % | 91 | 95 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 9.7. | Хезмәт шартлары буенча аттестация узган эш урыннары саны, берәмлек | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 9.8. | Иминлек паспортлары булган мәктәпләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 9.9. | Янгын сигнализациясе булган мәктәпләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| **10. Авыр тормыш хәлендә калган балаларга ярдәм итү** | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10.1. | Гаилә иминлеген профилактикалау буенча семинарлар һәм тренинглар үткәрүдә катнашучы мәктәпләр өлеше (процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 10.2. | Хокук саклау отрядлары булган мәктәпләр өлеше, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 10.3. | Мәктәп укытучылары һәм район җитәкчеләре арасында җәмәгать тәрбиячеләре санын арттыру | 10 | 15 | 20 | 20 | 20 | 25 |
| 10.4. | Пандуслар булган белем бирү учреждениеләре өлеше, % | 22,6 | 25 | 30 | 30 | 30 | 35 |
| 10.5. | Сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән эшләүче педагогларны семинарлар, консультацияләр, конференцияләр белән колачлау | 60 | 65 | 65 | 70 | 70 | 72 |
| 10.6. | Медицина күрсәткечләрен исәпкә алып, читләштерелгән укыту оештырылган сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар, шул исәптән инвалидлар | 11 | 11 | 14 | 14 | 14 | 14 |
| 10.7. | Инвалид балаларны читләштерелгән укыту технологияләре буенча яңадан әзерлек укулары узган педагоглар саны, кеше. | 16 | 10 | 10 | 12 | 12 | 14 |
| 10.8. | Массакүләм шәһәр һәм республика чараларына җәлеп ителгән, шул исәптән инвалидлар декадасы кысаларында, сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар өлеше, % | 50 | 50 | 60 | 70 | 80 | 80 |
| 10.9. | Инклюзив белем бирү моделен гамәлгә кертү буенча сынау мәйданчыклары саны | 2 | 2 | 3 | 4 | 4 | 5 |
| 10.10. | Инклюзив укыту технологияләрен сынау буенча мәктәп-ресурс үзәкләре саны | 2 | 2 | 3 | 4 | 4 | 5 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.И.Гарифҗановка йөкләргә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1609009516

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин